# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге составына керүче Урта Нырты торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

14.11.2025 № 1

“Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәсе оештыруның гомуми принөиплары турында” 20.03.2025 елгы 33-ФЗ номерлы Федералҗ законы 45,69 статьялары, “Татарстан Респуҗликасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 26 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып 2025 елның 14 ноябрьндә узган гражданнар җыенында «2026 нче елда Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге составына керүче Урта Нырты торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгын кору, Урта Нырты торак пунктында янәшәдәге территорияне төзекләндерү)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 105 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 59 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 59 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге составына керүче Урта Нырты торак пунктында халык җыенын үткән дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип таныргa.

2. «2026 нче елда Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге составына керүче Урта Нырты торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгын кору, Урта Нырты торак пунктында янәшәдәге территорияне төзекләндерү)

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/nirti адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Олы Нырты авыл
җирлеге башлыгы Р.З.Сафаргалиев